**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы**

Зур Тигәнәле муниципаль бюджет төп гомумбелем бирү мәктәбе

| | | |
|---|---|---|
| «Каралды»<br>Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик берләшмәсе җитәкчесе<br>________ Ахметзанова И.Р.<br>Беркетмә № 1<br>29 нчы август 2018 нче ел | «Килешенде»<br>Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары<br>________ А.Н.Сайфутдинова<br>31 нче август 2018 нче ел | «Раслыйм»<br>Мәктәп директоры<br>________ И.Н.Галимов<br>Боерык № 58<br>31 нче август 2018 нче ел |

**Эш программасы**

**Татар эдэбияты, 9 нчы сыйныф**

*Тозеде : 1 квалификацион категорияле татар теле ,эдэбияты укытучысы Ахметзанова Илсоя Ринат кызы*

Педсовет утырышында каралды
Беркетмә №1, 31 нче август 2018 нче ел

2018-2019 нчы уку елы

Программа Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының төп базислы укыту планына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе Зур Тигәнәле төп гомуми белем бирү мәктәбенең 2018-2019 нче уку елына төзелгән укыту планына нигезләнде.

**5-9 нчы сыйныфларда татар теленнән төп гомуми белем бирүнең максатлары:**

1. Укучыларның башлангыч мәктәптә фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү.
2. Укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү.
3. Телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү.
4. Татар әдәби тел нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга, аларны тиешенчә куллана белергә өйрәтү, сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен аңлату.
5. Телнең милли мәдәниятнең чагылышы булуын, тел һәм тарих бердәмлеген аңлату, татар теленең милли-мәдәни үзенчәлегенә төшендерү; татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү.

**Төп бурычлар:**

1. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле белем бирүне дәвам итү.
2. Укучыларның сөйләм һәм язу культурасын үстерү, мөстәкыйль эшчәнлеген активлаштыру.
3. Баланың үзен тәрбияләү, үзе белән идарә итү, үз фикерен яклый алу сәләтен үстерү.
4. Текст һәм башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү.
5. Укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын камилләштерү.

**Формалаштырылган осталык һәм күнекмәләр (уку елы башына)**

1. Туры сөйләмне үз сөйләмеңдә файдалана белү, чит кеше сүзләрен диалог яки монолог формасында бирә алу; туры сөйләмгә бәйле тыныш билгеләрен дөрес куя, куелганнарына аңлатма бирә белү.
2. Кушма җөмләләрдән тиешенчә файдалану, аларның төрле төрләрен төзү, таләп ителгән төренә мисал китерү, җөмләгә һәм текстка өлешчә яки тулы грамматик анализ ясый белү, кушма җөмлә компопнентлары арасына тиешле тыныш билгеләрен кую, аларны дәлилләү; төрле төзелештәге кушма җөмлә җөмлә өлешләрен сөйләмдә тиешле интонация белән уку.
3. Тема эчендә диалог һәм монолог формаларында сөйли һәм яза белү.
4. Сыйфатлама, модальлек, эмоциональлек элементларын, стиль үзенчәлекләрен кулланып, укыту һәм тәрбия максатларына уңай җавап бирерлек темаларга сочинение һәм изложение яза алу; язманы камилләштерә (тулыландыра, төзәтмәләр кертә) алу.
5. Җыелыш яки берәр утырышның беркетмәсен яза белү.

6. Мәктәп программасы таләп иткән күләмдә җөмлә составындагы сүзләргә фонетик, морфологик, грамматик анализ ясау, кушма җөмләләрне бер төрдән икенче төргә үзгәртә белү; кушма җөмләнең схемасын, төрен, иярчен җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше ягыннан төрен, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче аналитик һәм синтетик чараларны белү, баш һәм иярчен җөмлә арасына куелырга тиешле тыныш билгеләрен дөрес кую күнекмәләренә ия булу.

**Укучылар үзләштерергә тиешле осталык һәм күнекмәләр (уку елы ахырына)**

1. Милли телнең иҗтимагый тормыштагы әһәмиятен аңлау, телне саклау – милләтне саклауның төп өлеше икәнен үзләштерү.
2. Язылган текстларның стиль үзенчәлекләрен - аера, эчтәлеген аңлап укый белү; фәнни, рәсми, публицистик стильдә, матур әдәбият стилендә язылган башлангыч текст үзенчәлекләрен тоеп, язма текстта шуларны бирә белү.
3. Татар әдәби теленең үсеш үзенчәлекләрен күз алдына китерү; аралашу һәм үзара аңлашу чарасы буларак язма һәм сөйләмә тел үсештә булсын өчен, аның көндәлек кулланылышын тәэмин итү юлларын белү, ягъни телләр турындагы Законны тормышка ашыру юлларын үзләштерү.
4. Татар тел гыйлеменең татарча укытыла торган башка фәннәр белән бәйләнешен аңлата белү; татар әдәби телен ассимиляцияләнүдән саклау.
5. Татар теленең диалектлары һәм сөйләшләре турында гомуми төшенчәгә ия булу.
6. Тексттагы проблемаларны формалаштыру, текстта күтәрелгән проблемаларны үз дәлилләрен китереп аңлата белү.
7. Изложение һәм сочинениеләрне, сөйләм төренә туры китереп, төрле жанрда яза белү. Язмаларны сыйфатлама, модальлек, эмоциональлек элементларын, стиль үзенчәлекләрен кулланып тулыландыру һәм шомарта алу.
8. Текст яки аның берәр өлеше нигезендә конспект төзү, тезислар әзерли алу, кемгә дә булса характеристика яза белү.
9. Эш кәгазьләреннән хат, белешмә, мәкалә, расписка, акт, гариза һәм беркетмәләрне мөстәкыйль рәвештә яза алу.
10. Сәнгатьле уку, әдәби телдә сөйләм күнекмәләренә ия булу.

## Программаның эчтәлеге

| Эчтәлек | Сәгать саны | Диктант | Изложение | Сочинение | Б.С.Ү. |
|---|---|---|---|---|---|
| Фонетика. Сөйләм авазлары, аларның кулланылышы: авазларның охшашлануы, чиратлашуы; авазлар чиратлашканда, мәгънәнең үзгәрүе | 2 | | | | |
| Дөрес сөйләү һәм язу: сүзнең әйтелеше һәм язылышы, сүз ярдәмендә белдерелгән мәгънә | 2 | | | | |
| Лексикология.Татар әдәби теленең сүзлек составы. Сүзнең лексик мәгънәсе, бер һәм күп мәгънәле сүзләр, сүзнең туры һәм кү-черелмә мәгънәләре. Синоним, омоним, антоним сүзләр. Фразеологизмнар. Про-фессионализмнар. Диалектизмнар. Неоло-гизмнар. Архаизмнар. Алынма сүзләр. Сүзлекләр. | 3 | 1 к. | 2 (теманы өйрәнү эчендә) | | |
| Сүз төркемнәре: мөстәкыйль мәгънәле сүз төркемнәре, ярдәмче сүз төркемнәре | 2 | | | | 1 -текст өстендә эш |
| Сүзләрнең ясалышы һәм язылышы: тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә, кыскартылма сүзләр | 2 | | | | |
| Кушымчалар: ясагыч һәм төрләндергеч кушымчалар, модальлекне белдерүче һәм бәйләгеч кушымчалар, бифункциональ кушымчалар; кушымчаларның язылышы | 2 | | | | |
| Гади җөмлә синтаксисы. Гади җөмлә синтаксисы.Сүзләр арасында мәгънә мөнәсәбәтләре: ияртүле һәм тезүле бәйләнеш. Җөмләдә кушымчаларның, теркәгечләрнең, кисәкчәләрнең, бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең язылышы; сставында аерымланган кисәге, аныклагычы, тиңдәш кисәкләре, гомумиләштерүче сүзе, кереш яки эндәш сүзе, өстәлмәсе булган җөмләләр; аларда тыныш билгеләре | 4 | | | | 1- әдәбият дәресен-дә язылган сочине-ниене тел, төгәллек һәм сөйләм матур-лыгы , грамоталы-лык ягыннан бергә-ләп тикшерү |
| Кушма җөмлә синтаксисы. Җөмләләр арасында тезүле һәм ияртүле бәйләнеш: тезмә һәм иярченле кушма җөмләләр; теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрдә бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре; аналитик һәм | 6 | | | | 2 с. –контроль изложение |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| синтетик иярчен җөмләле кушма җөмләләр, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүче аналитик һәм синтетик чаралар, аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре | | | | | |
| Стилистика һәм сөйләм культурасы. Стилистика. Әдәби сөйләм, аның стиль-ләре. Функциональ стильләр: матур әдә-бият стиле, аның лексик һәм грамматик үзенчәлекләре; көндәлек матбугат стиле, аның үзенчәлекләре; фәнни стиль, аны үстерү өчен кирәкле шартлар; рәсми стильгә хас үзенчәлекләр; эпистоляр стиль, аның телебез тарихында тоткан урыны.<br>Төрле сүз төркемнәренә тупланган сүзләрне сөйләмдә куллану. Грамматик синонимнар, аларның төрләре: морфоло-гик һәм синтаксик синонимнар. Морфо-логик синонимнарны сөйләмдә куллану үзенчәлекләре. Синтаксик синонимнаның үз эчендәге төрләре: сүзтезмәләрнең си-нонимлыгы, җөмлә кисәкләрен синони-мик куллану, бер һәм ике составлы җөм-ләләрнең синонимлыгы, фигыль юнәлеш-ләре белән бәйле синонимлык (актив һәм пассив төзелмәләр синонимлыгы), туры һәм кыек сөйләм синонимлыгы. Анали-тик һәм синтетик иярчен җөмләләрнең синонимлыгы, иярчен кисәк һәм иярчен җөмлә синонимлыгы, тезмә кушма җөм-ләләрне синонимик куллану.<br>Лексик һәм грамматик калькалар, аларның татар сөйләмендә кулланылышы.<br>Сөйләм культурасы, аның нигезләре: төгәллек, аңлаешлылык, чисталык, җый-наклык, аһәңлелек. | **19**<br>6<br>5<br>2<br>6 | 1 (те-ма-ны өй-рәнү эчен-дә)<br>1 к. | 2 | 1 | 1- конспект һәм тезис язу<br>1-үтенеч, ышанычна-мә язу<br>1- изложение язу. |
| Тел турында гомуми мәгълүмат. Телнең иҗтимагый әһәмияте. Тел үсеше турында гомуми мәгълүмат.Тел һәм тарих, хәзерге милли татар әдәби теленең тамырлары, милли та | **8** | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| тар әдәби теленең формалашуы. Хәзерге татар әдәби теленең үсеше.<br>Татар сөйләмә теленең диалектлары. Татар әдәби теленең сафлыгын, аһәңен, матурлыгын, гаиләдә һәм мәктәптә тәрбияви көчен саклау.<br>**Икетеллелек.** «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законы.<br>Хәзерге татар әдәби теленең үсеш үзенчәлекләре<br>Тел гыйлеменең әһәмияте, төп бүлекләре<br>Кабатлау | 4<br>2<br><br>2 | 1 к. | | | 1 –рецензия язу<br><br>2 –контроль изложение |
| Резерв | 2 | | | | |

## Календарь –тематик планлаштыру

| № | Дәрес темасы | Сәгать саны | Дата | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| 1 | Фонетиканың өйрәнү объ-ектлары һәм юнәлешләре. | 1 | | |
| 2 | Сөйләм авазлары, аларның кулланылышы. | 1 | | |
| 3 | Дөрес сөйләү һәм дөрес язу. | 1 | | |
| 4 | Сүзнең әйтелеше һәм язылы-шы. | 1 | | |
| | | | | |
| 5 | Татар әдәби теленең сүзлек составы. Сүзнең лексик мәгънәсе. Миниатюр изложение. | 1 | | |
| 6 | Фразеологизмнар, аларның кулланылышы. | 1 | | |
| 7 | Татар теленең кулланылыш өлкәсе һәм дәрәҗәсе ягын-нан сүзлек составы. Сүз-лекләр. | 1 | | |
| 8 | Гомуми белем һәм күнек-мәләрне тикшерүгә кереш контроль **диктант.** | 1 | | |
| | | | | |
| 9 | Хаталар өстендә эш. Сүз төркемнәре. Мөстәкыйль мәгънәле сүз төркемнәре. | 1 | | |
| 10 | *Бәйләнешле сөйләм үстерү.* № 1. Сәнгатьле уку, текст өстендә эшләү. | 1 | | |
| 11 | Сүз төркемнәре. Ярдәмче сүз төркемнәре. | 1 | | |
| 12 | Сүзләрнең ясалышы һәм язылышы. | 1 | | |
| 13 | Сүзләрнең ясалышы һәм язылышын ныгыту күне-гүләре. | 1 | | |
| 14 | Кушымчалар һәм аларның язылышы. | 1 | | |
| 15 | Кушымчаларның дөрес язы-лышын ныгыту күнегүләре. | | | |
| | | | | |
| 16 | Гади җөмлә синтаксисы. Сүзләр арасында мәгънә мөнәсәбәтләре. | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 17 | Б.С.Ү.№ 2. Тестлар ярдәмендә укучыларның белем сыйфатларын тикшерү. | 1 | | |
| 18 | Гади җөмләдә тыныш билгеләре. | 1 | | |
| 19 | Составында аерымланган кисәге, аныклагычы, тиң-дәш кисәкләре булган җөм-ләләрдә тыныш билгеләре. | 1 | | |
| 20 | Составында гомумиләште-рүче сүзе, кереш яки эндәш сүзе, өстәлмәсе булган җөм-ләләрдә тыныш билгеләре. | 1 | | |
| 21 | Б.С.Ү.№ 3. Әдәбият дәре-сендә язылган сочинениене тел, төгәллек һәм сөйләм матурлыгы, грамоталылык ягыннан бергәләп тикшерү һәм төзәтү. | 1 | | |
| 22 | Кушма җөмлә синтаксисы. Җөмләләр арасында бәйлә-неш. | 1 | | |
| 23 | Тезмә кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | 1 | | |
| 24 | Синтетик иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. | 1 | | |
| 25 | Аналитик иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билге-ләре. | 1 | | |
| 26 | Кушма җөмлә эчендәге тыныш билгеләрен кабатлау. | 1 | | |
| 27-<br><br>28 | *Бәйләнешле сөйләм үстерү.* № 4, 5. Контроль изложение.План төзү. Караламага язу.<br>Сочинение элементы белән контроль изложение язу. "Кеше бәхете". | 2 | | |
| 29 | Контроль изложение хата-лары өстендә эшләү. Кушма җөмлә синтаксисын ныгыту, кабатлау күнегүләре эшләү. | 1 | | |
| 30 | 2 чиреккә контроль эш | 1 | | |
| 31 | Хаталар өстендә эш. Әдәби сөйләм һәм аның стильләре. | 1 | | |
| 32 | Функциональ стильләр. Әдәби стиль. | 1 | | |
| 33 | *Бәйләнешле сөйләм үстерү* Конспект һәм тезис язу күнегүләре. | 1 | | |
| 34 | Публицистик стиль. | 1 | | |
| 35 | Фәнни стиль . | 1 | | |
| 36 | Рәсми стиль. | 1 | | |
| 37 | *Бәйләнешле сөйләм үсте-рү.* Үтенеч һәм ышаныч язу. | 1 | | |
| 38 | Сөйләмә стиль | 1 | | |
| 39 | Стилистиканың нигезе буларак синонимия. | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 40 | Морфологик һәм синтаксик синонимнар. | 1 | | |
| 41 | Синтаксик синонимнарның төрләре. | 1 | | |
| 42 | *Бәйләнешле сөйләм үстерү*. "Синонимнар" темасы буенча изложение. | 1 | | |
| 43 | Синтетик һәм аналитик җөмләләрнең синонимлыгы. | 1 | | |
| 44 | Тезмә кушма җөмләләрне синонимик куллану. Диктант. | 1 | | |
| 45 | Лексик һәм грамматик калькалар. | 1 | | |
| 46 | Лексик һәм грамматик каль-каларның татар сөйләмендә кулланышы. | 1 | | |
| 47 | Сөйләм төрләре.Сочинение-хөкем йөртү. " Мине уй-ландырган әсәр". | 1 | | |
| 48 | Сөйләм культурасы һәм аның нигезләре. | 1 | | |
| 49 | Сөйләм төгәллеге. Синоним-нарны куллануның әһәми-яте. | 1 | | |
| 50 | III чиректә үтелгән темалар буенча белем һәм күнекмә-ләрне тикшерүгә контроль диктант. | 1 | | |
| 51 | Хаталар өстендә эш. Сөй-ләмнең аңлаешлы булуы. | 1 | | |
| 52 | Сөйләмнең сафлыгы. Лексик берәмлекләрне урынлы кул-лану. | 1 | | |
| 53 | Сөйләмнең җыйнаклыгына төп таләпләр. | 1 | | |
| 54 | Сөйләмнең аһәңлелеге. Аһәңле сөйләмгә таләпләр. | 1 | | |
| 55 | "Сөйләм культурасы, аның нигезләре" темасына изложение "Чегән чишмәсе". | 1 | | |
| 56 | Тел үсеше турында гомуми мәгълүмат.Тел һәм тарих. Хәзерге татар милли әдәби теленең тамырлары. | 1 | | |
| 57 | Татар милли әдәби теленең формалашуы. Хәзерге татар әдәби теленең үсеше. | 1 | | |
| 58 | Татар сөйләмә теленең төп диалектлары, аларның язмы-шы. | 1 | | |
| 50 | Икетеллелек. "Татарстан Республикасы халыклары телләре турында " Татарстан Респуликасы Законы. | 1 | | |
| 60 | *Бәйләнешле сөйләм үстерү*. . Әдәбият дәресендә өйрәнелгән бер әсәргә | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | яки аның бер өлешенә рецензия язу. | | | |
| 61 | Тел гыйлеме фәне, аның төп бүлекләре. | 1 | | |
| 62 | Тел гыйлеменең  башка фән-нәр белән бәйләнеше, тормыштагы әһәмияте. | 1 | | |
| 63-64 | *Бәйләнешле сөйләм үстерү*  “Тел турында гомуми мәгълүмат, телнең иҗтимагый әһәмияте” темасын йомгаклауга контроль изложение. | 2 | | |
| 65 | Синтаксис һәм пунктуация, стилистика һәм сөйләм культурасы буенча үткән-нәрне кабатлау. | 1 | | |
| 66 | Еллык материалны гомумиләштереп кабатлау. | 1 | | |
| 67 | Еллык белем һәм күнекмәләрне тикшерүгә контроль диктант язу. | 1 | | |
| 68 | Хаталар өстендә эш.  Йомгаклау. | 1 | | |